**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Балтач авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Балтач авылы № 9 09 декабрь 2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының 2014 елның 16 августындагы91 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (18.11.2015 № 15, 16.12.2016 № 44, 23.04.2019 №131, 03.02.2020 № 157, 12.032021 № 23, 06.10.2021 № 35, 01.02.2023 № 76, 02.10.2023 №94,12.01.2024 №105, 23.04.2024 № 117 , 28.11.2024 №135 карарлар редакциясендә)

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында" 2025 елның 03 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Балтач авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының 2014 елның 16 августындагы91 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә ( 18.11.2015 № 15, 16.12.2016 № 44, 23.04.2019 №131, 03.02.2020 № 157, 12.032021 № 23, 06.10.2021 № 35, 01.02.2023 № 76, 02.10.2023 №94,12.01.2024 №105, 23.04.2024 № 117 , 28.11.2024 №135 карарлар редакциясендә) 4 бүлекнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«2. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә: вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәүче төркемнәре өчен, шулай ук җирле үзидарә органнарында вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яисә урта һөнәри белем булу;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы булу».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә" түбәндәге веб-адрес буенча http://aznakaevo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.Л.Хәбипов